Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чикләрен Киров өлкәсе чиге белән чиктәш җирдә Татарстан Республикасы чигенә туры китерү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында
бәяләмә

5.12.2025

Гавами тыңлаулар үткәрү урыны: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Кукмара ш., Ленин ур., 13 й., (Кукмара муниципаль районы Советының утырышлар залы).

Гавами тыңлауларны үткәрү датасы һәм вакыты: 5 декабрь, 2025 ел. 14 сәг. 00 мин.

Гавами тыңлаулар үткәрү инициаторы: Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башлыгы

Гавами тыңлаулар уздыру өчен нигез: «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Кукмара муниципаль районы Башлыгының «Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чикләрен туры китерү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында» 2025 елның 10 ноябрендәге 146 номерлы карары.

Гавами тыңлауларда каралган мәсьәләнең исеме: Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чикләрен Киров өлкәсе чиге белән чиктәш урында Татарстан Республикасы чигенә туры китерү

Гавами тыңлаулар турында халыкка хәбәр итү: Гавами тыңлаулар уздыру турында мәгълүмати хәбәр (Кукмара муниципаль районы башлыгының 10.11.2025 ел, №146 карары):

- Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында.

Гавами тыңлауларда катнашучылар саны турында белешмәләр: 26 кеше.

Гавами тыңлауларда каралган мәсьәлә буенча Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы яшәүчеләреннән язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кермәде.

Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча карар кабул ителде:

1. Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чикләрен Киров өлкәсе чиге белән чиктәш җирдә Татарстан Республикасы чигенә туры китерү мәсьәләсен хупларга.

2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советына Киров өлкәсе чиге белән чиктәш җирдә Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чикләрен Татарстан

Республикасы чигенә туры китерүгә халыкның ризалыгын белдерергә тәкъдим итәргә.

Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы бәяләмә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарылырга тиеш.

Район башлыгы С.Д. Димитриев